РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422980, г.Чистополь, ул.Бебеля, 129

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

тел. 5-43-60, тел/факс 5-43-70

**№46** **2019елның 04 нче сентябре**

***Постановление*** ***Карар***

Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы”
муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында
муниципаль вазыйфаларның һәм муниципаль
хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның беркетмә
чаралары белән бәйле рәвештә, хезмәт командировкаларында
һәм аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын
үтәүгә бәйле башка рәсми чараларда бүләк алу,
бүләкне тапшыру һәм бәяләү, реализацияләү (сатып алу)
һәм аны реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү
турында хәбәр итү тәртибе хакында”

«Вазыйфасына, яки вазыйфаи хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, хезмәт командировкаларында һәм аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле башка рәсми чараларда бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, реализацияләү (сатып алу) һәм аны реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү турында аерым категория затларның хәбәр итү тәртибе хакында”гы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 9 гыйнварындагы 10 номерлы карары нигезендә, “Вазыйфасына, яки вазыйфаи хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү турында аерым категория затларның хәбәр итү тәртибе хакында”гы Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 27 гыйнварындагы 94 номерлы боерыгына таянып,

**Карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларның һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның беркетмә чаралары белән бәйле рәвештә, хезмәт командировкаларында һәм аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле башка рәсми чараларда бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, реализацияләү (сатып алу) һәм аны реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү тәртибе хакында”гы Нигезләмәне кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.
2. Чистай муниципаль районы Башлыгының 2014 елның 15 февралендәге 20 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе Р.Р. Мәзгутовка йөкләргә.

**Чистай муниципаль районы**
**башлыгы** **Д.А. Иванов**

Чистай муниципаль районы
башлыгының 2019 елның
_____сентябрендәге
____номерлы карарына
Кушымта

Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларның һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның беркетмә чаралары белән бәйле рәвештә, хезмәт командировкаларында һәм аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле башка рәсми чараларда бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, реализацияләү (сатып алу) һәм аны реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү тәртибе хакындагы
Нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларның һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның (алга таба - муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, хезмәткәрләр) беркетмә чаралары белән бәйле рәвештә, хезмәт командировкаларында һәм аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле башка рәсми чараларда бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, реализацияләү (сатып алу) һәм аны реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү тәртибен билгели.

2. Әлеге Нигезләмәнең максатларында түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

“беркетмә чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә алынган бүләк” - муниципаль вазыйфа биләүче зат тарафыннан алына торган һәм хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүдән чыгып бүләк итүне гамәлгә ашыручы физик (юридик) затлардан алынган, канцелярия кирәк-яракларыннан тыш, беркетмә чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар кысаларында, күрсәтелгән чараларның һәр катнашучысына үзләренең хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәү максатларында, чәчәкләр һәм кыйммәтле бүләкләр, бүләк сыйфатында бирелгән чәчәкләр;

“беркетмә чаралары, хезмәт командировкалары һәм хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу” - вазыйфаи регламентта (вазыйфаи инструкциядә) каралган, муниципаль вазыйфа биләүче затның шәхсән, яисә физик (юридик) затлардан арадашчы аша бүләк алуы, шулай ук әлеге затларның эшчәнлек белән бәйле хокук үзенчәлекләрен, һөнәри хезмәт һәм хезмәт эшчәнлеге үзенчәлеген билгели торган федераль законнарда һәм башка норматив актларда билгеләнгән очракларда хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә.

3. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, вазыйфаи хәлләренә, яки хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә, башка рәсми чараларга бәйле рәвештә алынган бүләкләрдән тыш, физик (юридик) затлардан Россия Федерациясе законнарында каралмаган бүләкләр алырга хокукы юк.

4. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, хезмәткәрләр әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә, Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органының (алга таба – җирле үзидарә органы) хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә, беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алуның барлык очраклары турында хәбәр итәргә тиеш.

5. Беркетмә чаралары, хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар белән бәйле рәвештә, бүләк алу турындагы кушымта нигезендә төзелгән хәбәрнамә (алга таба - хәбәрнамә), бүләк алынганнан соң, 3 эш көненнән дә соңга калмыйча, хезмәткәр хезмәт эшчәнлеген башкара торган җирле үзидарә органының вәкаләтле структур бүлекчәсенә тапшыра. (алга таба - вәкаләтле структур бүлекчә). Вәкаләтле структур бүлекчә җирле үзидарә органы җитәкчесе итеп билгеләнә. Мөрәҗәгатькә бүләк бәясен раслаучы документлар (булган очракта), (касса чегы, товар чегы, бүләк өчен түләү (алу) турында башка документ) теркәлә.

Бүләк хезмәт командировкасы вакытында алынган очракта, ул бүләк алган затның хезмәт командировкасыннан кайтканнан соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

Әлеге пунктның беренче һәм икенче абзацларында күрсәтелгән срокларда хәбәрнамә бирү мөмкин булмаганда, муниципаль вазыйфаны биләүче хезмәткәргә бәйле булмаганлыктан, ул мәсьәләне хәл иткәннән соң, киләсе көннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

6. Хәбәрнамә 2 нөсхәдә төзелә, аларның берсе теркәлү турындагы тамга белән мөрәҗәгать иткән затка кире кайтарыла, икенче нөсхәсе бухгалтерлык исәбе турындагы законнар нигезендә төзелгән җирле үзидарә органы активларын керү һәм чыгару комиссиясенә (алга таба - комиссия) җибәрелә.

7. Бәясе документлар белән раслана һәм 3 мең сумнан артып китә торган бүләк, яки аның хезмәткәренә бәясе билгесез булган бүләк, структур бүлекчәнең җаваплы затына тапшырыла, ул аны үз чиратында кабул итү-тапшыру акты буенча саклауга, теркәү журналында хәбәрнамәне теркәгән көннән соң, 5 эш көненнән дә соңга калмыйча кабул итә.

8. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан алынган бүләк, бәясе нинди булуга карамастан, әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында каралган тәртиптә саклануга тапшырылырга тиеш.

9. Бүләкне кабул итү-тапшыру акты буенча тапшырганга кадәр, бүләкне югалткан, яки зыян китергән өчен, бүләк алган зат Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап тота.

10. Бухгалтерлык исәбенә бүләкне Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә кабул ителә. Аның бәясен билгеләү өчен, бүләкне исәпкә алу датасына гамәлдә булган базар бәясе, яки кирәк дип табылган очракта, комиссияне җәлеп итеп, тәңгәл шартларда шундый ук матди кыйммәткә тигез бәяләр нигезендә билгеләнелә. Базар бәясе турындагы мәгълүмат документаль, ә документаль раслау мөмкин булмаганда - эксперт юлы белән раслана. Бүләк, бәясе 3 мең сумнан артмаган очракта, аны кабул итү-тапшыру акты буенча тапшырган затка кире кайтарыла.

11. Вәкаләтле структур бүлекчәсе, билгеләнгән тәртиптә бухгалтерлык исәбенә алынган бүләкне, әгәр дә аның хакы 3 мең сумнан артып китсә, Татарстан Республикасының “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге милке реестрына кертүне тәэмин итә.

12. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат, бүләк тапшырган хезмәткәр, аны яллаучы (эш бирүче) вәкиле исеменә бүләк тапшырганнан соң, ике айдан да соңга калмыйча гариза юллап, сатып алырга мөмкин.

13. Вәкаләтле структур бүлекчә әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгәнчә, гариза кергән көннән алып 3 ай эчендә, бүләкнең сату хакын бәяләүне оештыра һәм язма рәвештә гариза биргән затка бәяләү нәтиҗәләре турында хәбәр итә. Шуннан соң, бер ай эчендә, гариза бирүче бүләкне әлеге бәяләү нәтиҗәсендә билгеләнгән хак буенча сатып ала, яки сатып алудан баш тарта.

14. Әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгәнчә гариза алынмаган бүләк, җирле үзидарә органнары эшчәнлеген тәэмин итү өчен, куллануның максатка ярашлылыгы турында комиссия бәяләмәсен исәпкә алып, җирле үзидарә органы тарафыннан файдаланылырга мөмкин.

15. Бүләкне куллануның максатка ярашлы булмавы ачыкланса, җирле үзидарә органы җитәкчесе бүләкне гамәлгә ашыру һәм сату (сатып алу) өчен аның хакын бәяләү турында карар кабул итә һәм ул Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә, торглар үткәрү юлы белән вәкаләтле структур бүлекчә тарафыннан оештырыла.

16. Сату (сатып алу) бәясен билгеләү, әлеге Нигезләмәнең 13 һәм 15 пунктларында каралганча, Россия Федерациясе законнары нигезендә, бәяләү эшчәнлеге субъектлары тарафыннан башкарыла.

17. Бүләк сатып алынмаган, яки гамәлгә ашырылмаган очракта, җирле үзидарә органы җитәкчесе бүләкне кабат реализацияләү турында, яки аны хәйрия оешмасы балансына түләүсез тапшыру, яки аны Россия Федерациясе законнары нигезендә юк итү турында Карар кабул итә.

18. Бүләкне сатудан (сатып алу) кергән акчалар Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге бюджеты кеременә Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә күчерелә.

органнарында муниципаль вазыйфаларның һәм
муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның
беркетмә чаралары белән бәйле рәвештә,
хезмәт командировкаларында һәм аларның хезмәт (вазыйфаи)
бурычларын үтәүгә бәйле башка рәсми чараларда
бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, реализацияләү (сатып алу)
һәм аны реализацияләүдән кергән акчаларны
күчерү турында хәбәр итү тәртибе хакындагы
Нигезләмәгә кушымта

**Бүләк алу турында хәбәрнамә**

___________________________________
(вәкаләтле вәкил исеме
___________________________________
структур бүлекчәсе
___________________________________
җирле үзидарә органы

_________________________________
__________________________________
(ФИО, вазыйфасы)

«__» ________ 20__ елда бүләк алу турында хәбәрнамә.

Бүләк алу турында хәбәр итәм__________________________________________
(бүләк алу датасы)
бүләк(ләр) __________________________________________________________
(беркетмә чарасының, хезмәт командировкасының
һәм башка рәсми чара исеме,
аны уздыру урыны һәм вакыты)

| Бүләкнең атамасы | Бүләкнең характеристика-сы, аның тасвирламасы | Предметлар саны | Бәясе, сумнарда <*> |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |
| 2. | | | |
| 3. | | | |
| Барлыгы | | | |

Кушымта: __________________________________________ _____ биттән тора.
(Документ исеме)

хәбәрнамә
тапшырган зат _______ __ __________________________ «__» __ 20__ел
(имза) (имза расшифровкасы)

Кабул иткән зат _________ __________________________ «__» ____ 20__ ел.
(имза) (имза расшифровкасы)

Гаризаларны теркәү журналында теркәү номеры _____________

«__» _________ 20__ ел.

--------------------------------
<*> Бүләк бәясен раслаучы документлар булганда тутырыла.

**Татарстан Республикасы**
**Чистай муниципаль районы башлыгы**
**карары проектына карата**
**КИЛЕШТЕРҮ КӘГАЗЕ**

**1.Документның исеме** «Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның беркетмә чаралары белән бәйле рәвештә, хезмәт командировкаларында һәм аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле башка рәсми чараларда бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, реализацияләү (сатып алу) һәм аны реализацияләүдән кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү тәртибе хакында”

**2. Проектны әзерләде** Чистай муниципаль районы башлыгы ярдәмчесе

Ефимов А. Т

**3. Җитәкче** ____________________________________________

____________________________ **2019 елның « 4» нче сентябре**

(имза)

**Проектны тапшыру датасы:** **2019 елның « 4» нче сентябре**

**4. Бүлек һәм хезмәт җитәкчеләренең визалары:**

| Килештерүче бүлекчәнең исеме, вазыйфасы | Ф.И.О. | Килештерү гә тапшыру вакыты | Имза, килештерү датасы. Кыскача эчтәлеге, искәрмәләр. | искәрмәләр төзәтелде, имза, датасы |
|---|---|---|---|---|
| ЧМР Советы Аппараты җитәкчесе | Р.Р. Мәзгүтов | | | |
| ЧМР Советының җирлекләрнең ММИ белән хезмәттәшлек итү бүлеге башлыгы | И.Ш.Садриева | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

**5. Төзәтмәләр кертү өчен тапшырылды**

______________________________________________________________

(датасы, кем аркасында)

**6. Имзага тапшырылды**

______________________________________________________________

(дата,  гомум бүлек визасы)